

22 апрель конне Ләмберә авылынын «Алмаз» мәдәни-спорт vзәгендә Габдулла Тукай ижатына багышланган «Аулак ой» милли фольклор бәйрәме булып узган. Анда районнын татар мәктәпләре вәкилләре катнашкан.
Бераз мәгълумат. Быел милләтебезнен боек шагыйре Габдулла әфәнде Тукаев тууына 26нчы апрельдә 139 ел тулды. Бу конне Казан губернасы Казан оязе Кушлавыч авылында (хәзерге ТР Арча районы) указлы мулла Мохәммәдгариф Мохәммәтгалим улы белән Бибимәмдvдә Зиннәтулла кызы гаиләсендә булачак шагыйрь доньяга килә.

Габдулла Тукай кыска гомерендә дә милли поэзиянен классик әсәрләрен тудырды. Ижаты vзенен кvпкырлы, кин колачлы булуы белән тан калдыра. Шагыйрь кvп гасырлык татар әдәбиятынын, шәрекъ поэзиясенен гуманистик традицияләренә, рус классикасынын идея-эстетик казанышларына таянган, халык авыз-поэтик ижатынын ин саф чишмәләреннән коч һәм илһам алган. Ул татар әдәбиятында критик реализм әдәбиятын башлап жибәргән, милли әдәби поэтик телне тудыручы, рус классикасын татар теленә тәржемә итvдә беренче югары vрнәкләрне биргән талант, әдәби тәнкыйтьне һәм татар балалар әдәбиятын нигезләvче.
Габдулла Тукайга багышлап vткәрелгән «Аулак ой» фольклор бәйрәмендә Ләмберә районынын Аксён, Кривозерье, Пензятка урта, Черемиш, Татар Тавла топ мәктәпләре коман



даларынын бишәр укучысы коч сынашкан. Мәсәлән, Татар Тавла топ мәктәпне Салькаева Сафина, Абузярова Зарина, Муртазина Азалия, Байгельдина Аида, Алмакаева Айша, Альфия Фатих кызы Муртазина житәкчелегендә, команданы тәкъдим иткәннәр. Альфия Фатих кызы бәйрәм турында:
- Бәйрәмнен тематикасы боек татар шагыйре Габдулла Тукай ижатына багышланган иде. Катнашучылар тирән хис һәм артистлык белән классик шигырьләрен укыдылар, халык жырларын башкардылар, татар мәдәниятенен байлыгын һәм тирәнлеген кvрсәттеләр. “Аулак ой”нен йомгаклау аккорды Габдулла Тукайнын “Туган тел” шигыренә язылган жырны телгә гим иттереп тантаналы башкару булды. Анын тирән эчтәлекле юллары ана сvзенә карата дулкынланучан монәсәбәтен, мәдәни мирас белән горурлануын һәм туган

телгә карата уртак мәхәббәтен чагылдырды. Өлеге чара рухи бердәмлек, милләтен белән горурлану, телләрне һәм гореф-гадәтләрне саклауга этәргеч булды.

**Наилә НАСЫРОВА**